**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№126**
**16.01.2019**

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 17 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 маддәсе, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 нче карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезнамәнең 5 пунктчасы, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 нче карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр инфраструктурасын төзекләндерү дирекциясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган шәһәр инфраструктурасын карап тоту һәм ремонтлау мәсьәләләре буенча консультация хезмәте күрсәтүгә тарифны, өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, 2280,30 (ике мең ике йөз сиксән) сум 30 тиен күләмендә расларга.
2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ә. Кыямовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин